Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 15 19 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1,2 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлауга;

– Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (юлларны кардан чистарту, эшләр өчен шартнамә буенча түләү) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина